5 стр 40 от 3 10 14 г.

4 октябрь - Корбан гаете

Хөрмәтле «Авылым тавышлары»н укучыларыбыз! Хәзер мөселман халкы өчен бик кадерле һәм әһәмиятле ай — Зөлхиҗҗә ае — бара. Иртәгә, **4 октябрь көнне, Корбан бәйрәме** *булачак. Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне аеруча мөһим көннәр санала. Зөлхиҗҗә аенда мөселманнар хаҗ кылалар, айның тугызынчы көне исә — Гарәфә көне. Хәдисләрдән аңлашылганча, Зөлхиҗҗәнең беренче ун көне — Аллаһы Тәгаләнең иң яраткан көннәре, бигрәк тә Гарәфә көне бик кадерле вакыт булып тора. Шуннан хаҗ сәфәрендә булмаучылар бу көнне ураза тотарга тырышсыннар. Шулай ук, бу көннәрдә мөселманнар күбрәк гыйбадәт кылырга, сәдакалар бирергә һәм гөнаһларга тәүбә итәргә омтылсыннар. Димәк, без мондый изге вакытларны Аллаһы Тәгаләнең биргән олы бүләге итеп кабул итәргә һәм һәр мизгелнең кадерен белеп уздырырга тиешбез.*

КОРБАН ВАКЫЙГАСЫ

Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең ерак бабасы Ибраһимнән: «Әгәр дә миңа угыл бала бирсәң, мин шул баламны корбан итеп чалырга да әзер», — дигән сүзләр белән нәзер әйттерде.

Ләкин Аллаһы Тәгалә бәндәләрнең каннарын түгүче түгел, ул бары Ибраһим галәйһиссәләмне шул рәвешчә сынады. Ибраһим сынауны югары сыйфатта үтте. Аллаһ аннан разый булды. Исмәгыйль галәйһиссәләмне әтисе корбан итеп чалырга алып барганда, шайтан: «Сине атаң мәйданга алып бармый, чалырга алып бара», — дип Ибраһимнең Раббысына әйткән нәзерне үтәвенә каршы чыкмакчы булды. Шундый хәлдә дә Исмәгыйль: «И, әтием, Аллаһы Тәгалә нәрсә боерган булса, шуны эшлә, иншә Аллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табарсың», — дияргә үзендә көч тапты. Үз баласын суярга алып бара торган атаның һәм суелырга тиеш булган баланың иманын Аллаһы Тәгалә менә шулай сынады. Инде чалам дигәндә, Ибраһимгә: «Йә, Ибраһим! Раббыңа әйткән нәзереңдә тугрылыклы булуыңны исбатладың. Аллаһ синнән разый булды. Инде корбан итеп улыңны түгел, куй чал», — дигән нида килде. Шул вакыттан бирле бу вакыйга безгә бәйрәм булып калды.

Корбан бәйрәме алдыннан — 9-нчы көн — Гарәфә көнендә хаҗ кылучылар Мәккә янындагы Гарәфә тавына баралар һәм тау итәгендә намаз укыйлар.

10-нчы көн Корбан бәйрәме.

11-13 көннәр — Тәшрикъ көннәре. Зелхиҗҗәнең бу көннәре — бәйрәм көннәр.

Корбан — «Аллаһка якын булу» дигән сүз. Без һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә якын булырга тиеш. Ә нәрсә белән якын булабыз соң? Аллаһы Тәгаләгә чалган корбаннарыбызның ите дә, сөяге дә, мае да, йоны да ирешми бит.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйткәненчә: «... Аллаһы Тәгаләгә күңелләрегездәге иманнарыгыз, ихласларыгыз ирешә...».

«Ускудар» мәчетендә ватанпәрвәрлекне пропагандаладылар

Сентябрь аеның 28-нче көнендә Республика Мордовия мөселманнарының рухи җитәкчелегендә ватанпәрвәрлекне пропагандалауга багышлаган җаваплы эшләр үтте. Мөфти Зәки Абдулкарим улы Айзатуллин җитәкчелегендә яшь буында ватанпәрвәрлекне тәрбияләүдә ислам диненең әһәмиятлеге турында семинар барды. Мондый бүгенге көндәге актуаль темага сөйләшүгә күренекле иҗтимагый һәм дини хезмәткәрләр катнаштылар: Республика Мордовиянең Баш Администрациясе иҗтимагый бәрләшмә бүлегенең җитәкчесе Николай Иванович Салтаев, республикабызның милли сәясәт министрның беренче урынбасары Александр Иванович Карыгин. Шулай ук бу семинарга республиканың мәгариф министрлыгының, военкоматның, яшьләр комитетының, ветераннар оешмасының, РМ-ның мөселманнар рухи җитәкчелегенең, республиканың «Өзләү» оешмасының, «ДОСААФ России»-нең региональ бүлегенең, «Солдат аналары комитеты»-ның региональ иҗтимагый оешмасы вәкилләре дә, укытучылар һәм эшмәкәрчеләр кушылдылар. Аларның арасында безнең районда туганнар да бар иде: Бөтенроссия иҗтимагый ветераннар оешмасының региональ бүлегенең җитәкчесе Ф.И. Жалимов һәм «Юлдаш» КФХ-ның башы Р.А. Фетхуллов.

Семинар яшь буынчылар арасында ватанпәрвәрлекне пропагандалау максатына дип оештырылды. Чыгыш ясаучы кунакларны йөздән артык яшь егетләр бик кызыксынып тыңладылар. Мәсәлән, яшь үсмерләргә мөрәҗәгать итеп, Зәки—хазрәт әйтте: «Ватанпәрвәрлек — безнең тормышыбызның рухи нигезе, ул — азатлыкка һәм илебезнең чәчәк атуына безнең омтылышыбыз. Ислам динендә илне сөю — бик зур әһәмиятле урынга куела. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең әйткәненчә, Ватанны сөю — мөселман иманының бер билгесе...». Үсеп килә торган буынга башка кунаклар да мөрәҗәгать итеп, ватанпәрвәрлекнең әһәмиятлеге турында сөйләделәр. Шулай ук, семинарга катнашучылар ир балаларга гаскәри хезмәтнең изге бурычлыгын аңлатырга тырыштылар. Кара каршы итеп, гаскәри хезмәт турында үзләренең фикерләре белән яшь егетләр дә бүлештеләр. Ринат Миняев һәм Абдулкәрим Абушаев яшьтәшләренә мөрәҗәгать иттеләр. Гаскәри хезмәт зур тормыш тәҗрибәсен бирә, батырлык һәм тәвәккәллеккә өйрәтә, — диделәр бу егетләр.

Чараның барышында ир балаларга солдатларның тормышлары, хезмәте турында видеофильм күрсәттеләр. Яшь сәләт иясе Али Айзатуллин призывникларга багышлаган шигырь укып алды. Семинар беткәч, Мордовия Республикасы мөфтие Зәки хазрәт Айзатуллин семинарга катнашучылар өчен тәмле сый-хөрмәт оештырды.

Авылым тавышлары

Выпуск № 49

Дорогие братья и сестры!

Сердечно поздравляю вас с наступающим священным праздником Курбан-байрам. Это торжество несет с собой светлую радость укрепления веры, обретения нового духовного опыта, внутренней гармонии. В эти благословенные дни в мечетях звучат торжественные азаны, все правоверные мусульмане возносят свои молитвы Всевышнему. Праздник Ид аль-Адха несет в себе высокие духовные и нравственные ценности ислама. Он олицетворяет идеалы добра, милосердия и справедливости. В этот благословенный день мусульмане раздают мясо жертвенных животных, проявляют усердие в богослужении и совершении благих дел, оказывают взаимное внимание и заботу. Как гласит Священное Писание: милостыня – это путь преодоления трудностей. Оказывая помощь и благодеяние нуждающимся, каждый из нас поддерживает их, вселяет в души счастье, сеет в их сердцах зерна милосердия и сострадания.

Пусть Курбан-байрам прибавит нам сил и вдохновения, настроит на добрые дела и поступки, даруя радость и надежду в каждый дом, в каждую семью! Да примет Всевышний Аллах принесенные нами в этот священный день жертвоприношения.

Желаю вам душевного спокойствия, мира, здоровья и благополучия!

Муфтий Централизованной религиозной организации Региональное духовное управление мусульман Республики Мордовия при Центральном духовном управлении мусульман России Зяки Абдулкаримович Айзатуллин.

Хадисләр

Бер көнне Рәсүл әкрам галәйһиссәләм хәзрәтләре янына бер кеше килеп, болай дип әйтте: «Әй Аллаһның рәсүле, бер хатын-кыз турында сөйлим әле сезгә, ул күп намазлар укый, күп ураза тота, сәдакасын да күп бирә, әмма ямап сүзләр һәм усал теле белән күршесен бик рәнҗетә», — диде. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Ул җәһәннәмдә булачак», — диде. Теге кеше сорауын дәвам итте: «Икенче бер хатын-кыз турында сөйлим әле сезгә, ул күп намазлар укымый, күп ураза тотмый, сәдакасы да зур түгел, әмма мохтаҗларга ризыгын бүлеп өләшә һәм күршеләрен рәнҗетми, бу хатын-кыз турында нәрсә дип әйтәсез?» — диде. Аллаһның илчесе галәйһиссәләм үзенең җавабында: «Ул җәннәт иясе», — диде.

(Әл-Газали (безнең заман галиме) «Хулюк әл-мөслим»)

САБЫРЛЫК БАЙЛЫК

Сабыр булу иргә яхшы һөнәрләр,
Сабыр булган кешене Хак сөярдер.

Хакның рәхмәтләре һәр чак, син ишет,
Сабыр иткәннәргә булыр, и егет.

Барча күңдәмлекнең башыдыр сабыр,
Сабыр иткәнне Хак байлыкка сарыр

Мөхәммәдьярның Нуры содур (Күңелләр нуры) әсәреннән

ВНИМАНИЮ ЖИТЕЛЕЙ И ГОСТЕЙ ЛЯМБИРЯ!

По информации имама Лямбирской соборной мечети Ряшит-хазрята Сайфуллова, торжественное праздничное богослужение в Лямбирской мечети начнется в **7.30 утра 4 октября.**

Битне оештырды Умида Баймашева.